# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 21.10.2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Мәндей авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 21 октяберендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2023 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Яңа ел, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне);
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (янгын сүндерү җиһазлары һәм материаллары сатып алу);
- зиратта хуҗалык бинасы өчен материаллар сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 132 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 109 кеше кергән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 109 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы составына керүче Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй авылында узган халык җыенын халык җыенын утте дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.
2. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Яңа ел,  Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне);

- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (янгын сүндерү җиһазлары һәм материаллары сатып алу):

- зиратта хуҗалык бинасы өчен материаллар сатып алу.

3.Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.  һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәндәй авылы, Ялантау ур., 36б йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдулавыл җирлеге башлыгы: Н.А. Фатхетдинов